ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.05.2021 с.Старое Дрожжаное №195

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын (балалар бакчаларын) гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 28 июнендәге 275 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.9, 2.1, 2.3, 2.5 һәм 2.9 пунктларда** «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программалары - мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы («Российская газета» № 238, 23.10.2013) Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 елның 30 августындагы № 1014 боерыгы сүзләрен «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программалары - мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2020 елның 31 июлендәге 373 номерлы боерыгы сүзләренә алмаштырырга;

**2.5 пунктындагы 1 пунктчасының 4 абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит ил дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар һәм аларның рус теленә нотариаль танықланган тәрҗемәсе;»;

түбәндәге эчтәлектәге **ундүртенче абзац белән тулыландырырга:**

«-гражданлык хәле актларын теркәү органнары яисә Россия Федерациясенең консул учреждениеләре тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклыклар;».

2. Әлеге карарны Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырырга (PRAVO/TARSTAN.RU).

Башкарма комитет
Җитәкчесе: Д.А. Сатдинов